КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 сентябрь г.Казань № 861

2021 елда шәһәр эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү чыгымнарының 50 процентын каплау буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елда шәһәр эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү чыгымнарының 50 процентын каплау буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин